# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында үзара салым кертү турында**

27 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Урыс торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылганнар, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1.Урыс авылындагы зират территориясен саклау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2.Урыс авылында суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

3.Урыс авылында урамнарны грейдирлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4.Урыс авылында прицеп һәм хуҗалык инвентарын саклау өчен бина төзү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

3.Җыен нәтиҗәләрен Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://menzelinsk.tatarstan.ru хокукый

мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan. кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы ________________ И.С. Аксюкова
(имза)